КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 5 ноябрь г.Казань № 995

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 август, 687 нче; 2020 ел, 2 сентябрь, 774 нче; 2020 ел, 18 сентябрь, 847 нче; 2020 ел, 29 октябрь, 970 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 4 нче пунктның алтынчы абзацына «территорияләрендә» сүзләреннән соң «, шулай ук торак пунктлардан читтә урнашкан юл сервисы объектларында» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин